Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Тойкинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района
ул. Джалиля, д. 19, село Тойкино,
Азнакаевский район, 423302

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Туйкә авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Җәлил урамы, 19нче йорт, Туйкә авылы,
Азнакай районы, 423302

Тел. (факс) 8(85592) 45-0-89; e-mail: Toy.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
«22» октябрь 2021 ел

КАРАР
№ 16

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге башкарма комитетының 29 июлендәге 12 номерлы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге башкарма комитетының 29 июлендәге 12 номерлы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2 - 10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта федераль мәгълүмат адреслы системасының дәүләт адреслы реестрын алып баруга һәм эксплуатацияләүгә бәйле кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмати адреслы система турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 декабрендәге 1221 номерлы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында» Федераль закон белән төгәл тәңгәлләштереп кулланыла.»;

1.2. 1.5 пунктының 11-17 абзацлары. 3-9 абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4-7 пунктчаларында «башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки башкарма комитет»сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның башкарма комитеты яисә җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.4 пунктында «башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны " Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Р.Р.Закирова